**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАКЫРЧЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**КАРАРЫ**

16 январь 2019 ел № 2

**Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Бакырчы авыл җирлеге муниципаль норматив хокукый актлары проектларының көйләү йогынтысын бәяләүне уздыру һәм муниципаль норматив хокукый актларга экспертиза ясау турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, "Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларының көйләү йогынтысын бәяләүне уздыру һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына экспертиза ясау тәртибе турында" 2014 елның 7 мартындагы 14-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Бакырчы авыл җирлеге башкарма комитеты карар итә:

1.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Бакырчы авыл жирлеге Башкарма комететының 2017 елның 12 маендагы 6 номерлы «Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Бакырчы авыл җирлеге муниципаль норматив хокукый актлары проектларының көйләү йогынтысын бәяләүне уздыру һәм муниципаль норматив хокукый актларга экспертиза ясау турындагы нигезләмәне раслау хакында» карары белән расланган, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Бакырчы авыл җирлеге муниципаль норматив хокукый актлары проектларының көйләү йогынтысын бәяләүне уздыру һәм муниципаль норматив хокукый актларга экспертиза ясау турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.4 пункт үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының рәсми сайтында җирлек бүлегендә урнаштырырга

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Бакырчы авыл җирлеге башлыгы Ф.Х.Валиев**